ЯКШӘМБЕ
18 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 40 (5840)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ЯҢА НОРМАЛАРНЫ ЯХШЫ ҮЗЛӘШТЕРИК

Хезмәт җитештерүчәнлегенең бишьеллык планын 4 елда үтәү турында Москва инструментальщиклары мөраҗәгате бөек социалистик Ватаныбызда гаят зур күтәренкелек белән, массаның политик һәм производство активлыгының яңа күтәрелеше белән каршыланды. Предприятиеләрдә мона кадәр яшәп килгән нормаларны яңарту, эш башыннан эшләү буенча бәяләрне карап чыгу, барыннан да элек, хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югары күтәрүгә, илебезнең экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгытуга, халкыбызның тормышын тагын да яхшыртуга юнәлтелгән. Моны безнең бөек халкыбыз яхшы аңлый.

Предприятиеләребездә яңа нормалар, яңа бәяләр кертү—ул гаят әһәмиятле һәм җаваплы эш. **Чөнки яңа „техник нормалар, алар—регулярлаучы, производствода эшчеләрнең киң массаларын эшчеләр сыйнфының алдынгы элементлары тирәсенә оештыручы зур көч“.**

Бөек юлбашчыбыз, остазыбыз иптәш Сталинның бу тарихи күрсәтмәсе практикада расланды. Бу күрсәтмәне тормышка ашыру хезмәт җитештерүчәнлегенең яңа күтәрелешен тәэмин итте һәм итә.

Техник норма ул производствоның бүгенге торышын, техниканы үзләштерүнең дәрәҗәсен чагылдыра. Ә безнең социалистик индустрия бер урында таптанып тормый. Ул туктаусыз алга бара, яңадан-яңа һәм куәтле техника белән баетыла. Массаның иҗади хезмәт активлыгы производствоны рационаллаштыру өлкәсендә зур яңалыклар кертте һәм кертә. Бездә стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары—күп станокларда эшләү, берничә профессияне үзләштерү хәрәкәте туды. Хәзер киң урын алган бу хәрәкәт үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә.

Болар барсы да бер нәрсә турында, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең яңа мөмкинлекләре турында, моңа кадәр яшәп килгән техник нормаларның хәзер искерүе, аларны яңа, югарырак нормалар белән алмаштыру кирәклеге турында сөйлиләр. Меңнәрчә, миллионнарча алдынгы кешеләребезнең техник нормаларны системалы рәвештә арттырып үтәүләре әнә шуны таләп итә.

Яңа нормалар һәм яңа бәяләр кертү Татарстан республикасы предприятиеләрендә дә зур күтәренкелек һәм активлык белән каршыланды. Байтак кына предприятиеләрдә илебезнең мактаулы кешеләре—стахановчылар һәм ударниклар тарафыннан яңа нормалар беренче көннәрдә үк арттырып үтәлә башланды.

Мисаль өчен Серго заводын алыйк. Монда яңа нормалар, яңа бәяләр мәсьәләсе эшчеләрнең һәм инженер-техник работникларның гомуми җыелышларында тикшерелде. Хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югары күтәрүгә юнәлтелгән бу чараның политик әһәмияте һәрбер хезмәт иясенә җентекләп аңлатылды. Завод коллективы бу яңалыкны бердәм рәвештә яклады.

Нәтиҗә күз алдында. Иптәш Кузьмин җитәкчелек итә торган цехта эшләүче, Шәһәр Советы депутаты иптәш Вахомин бер үзе өч кеше хезмәтен башкарып, яңа норманы 180—200 процент итеп үти. Берьюлы ике фрезер станогында эшләүче Маслов, Максимова, строгальщик Юсупов, шлифовщик Игнатьев иптәшләр көнлек норма үтәлешен 200—300 проценттан, токарь Бушев, Гыйлманов, Корчагин һәм дистәләрчә башка иптәшләр 150—200 проценттан киметмиләр. Завод цехларында, бригадаларда яңа нормаларны үзләштерү һәм аларны арттырып үтәү өчен көрәш көннән-көн киң колач ала.

Нормаларны һәм бәяләрне яңадан карап чыгу Ленин исемендәге заводта да оешкан рәвештә үтте. Эшчеләр һәм инженер-техник работниклар бу эшне тиз һәм яхшырак үзләштерү буенча 20 дән артык такдим керттеләр. 1 нче февральдән завод яңа нормалар буенча эшли башлады һәм практик эш нәтиҗәләре яңа нормаларның да чик булып тормаганлыгын күрсәтте. Иптәш Гарнцева бригадасы һәрбер аппаратта норманы 130—140 процент итеп, Гаяз һәм Фатыйх Фәрзиевләр 150—160 процент, Гәрәев, Низамов һәм башка иптәшләр 160—170 процент итеп үтиләр. Ремонт-механика мастерскойларында хезмәт җитештерүчәнлеген быел план буенча 30 процентка күтәрү билгеләнгән иде. Коллектив аны 35 процентка җиткерергә карар бирде һәм үзенең йөкләмәсен эш белән ныгыта. Үз нормаларын 150—200 процент итеп үтәүче токарь Вавилов, Филиппов, Петушков, слесарь Митрофанов кебек иптәшләрне монда күпләп санарга мөмкин. Мастерскойларда яңа нормаларны тагын да югарырак итеп үтәү өчен кайбер оештыру-техник чаралар үткәрелә.

Ләкин бу эш барлык предприятиеләрдә дә яхшы тора дип, әйтеп булмый әле. Мәсәлән, җитен комбинатында, язу машиналары заводында һәм Серго Орджоникидзе исемендәге заводта бу эшнең торышы һич канәгатьләнерлек түгел. Монда яңа нормалар, яңа бәяләр ныклап тикшерелмәгән, массага киң рәвештә аңлатылмаган. Яңа нормаларны үтәү өчен тиешле шартлар тудыру буенча билгеләнгән практик чаралар тормышка бик акрын ашырылалар.

Предприятиеләребездә яңа нормалар, яңа бәяләр буенча эшли башлау орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгына хәзерлек эшләре киң колач алган чорга туры килде. Юбилей алды ярышын яңа нормаларны большевикларча үзләштерү өчен көрәш билгесе астында алып барырга кирәк.

Яңа нормаларның якын арада барлык эшчеләр тарафыннан арттырып үтәлүенә ирешү, моның өчен кирәк булган барлык шартларны тудыру, стахановчылар һәм ударниклар тарафыннан кертелгән күп сандагы кыйммәтле такдимнәрне җитез рәвештә тормышка ашыру, стахановчылар мәктәпләренең рольләрен күтәрү, нормаларын үти алмаучы эшчеләргә практик ярдәм оештыру—партия, профсоюз оешмаларыннан, хуҗалыкчылардан әнә шулар таләп ителә.

Яңа нормаларны большевикларча үзләштерү нигезендә, хезмәт җитештерүчәнлегенең яңа күтәрелешен тәэмин итик! Орденлы республикабызның XX еллыгын яңа уңышлар белән каршылыйк! Ярты еллык планның һәрбер предприятие тарафыннан арттырылып үтәлүен тәэмин итик!

БОЛГАРИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЯҢА СОСТАВЫ

СОФИЯ, 16 февраль. (ТАСС). Болгария телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, профессор Богдан Филов Болгариядә яңа кабинет төзегән. Кабинетка баш министр һәм мәгариф министре булып Богдан Филов, чит ил эшләре министре булып—элек Белградтагы илче Иван Попов, эчке эшләр министре булып—Габроеский (хөкүмәтнең элекке составында юл эшләре министре), юл эшләре министре булып—адвокат Горанов кергәннәр.

Калган министрлекләрдә элекке состав министрләре калган.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

16 нчы февральдә Карелия бугазында безнең гаскәрләрнең уңышлы хәрәкәтләре киңәюдә дәвам итте. Дошман безнең частьләргә контратака ясарга маташты, ләкин барлык участкыларда зур югалтуларга дучар ителеп алып ташланды. Безнең частьләр сугышып Лепясуо станциясен һәм **Кямяря** станциясен алдылар.

Үткән көн эчендә безнең гаскәрләр дошманның ныгытылган 22 оборона пунктын алдылар, шуларның икесе тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Безнең гаскәрләрнең 7 көнлек һөҗүме вактында дошманның без алган ныгытылган пунктларындагы югалтулары—420 пулеметтан һәм 170 орудиедән гыйбарәт.

Фронтның башка участкыларында разведчикларның эзләнүләре һәм кайбер урыннарда пехота частьләренең бәрелешләре булды.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 5 самолеты бәреп төшерелде.

чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 16 февраль. Кичә көндез фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмаганлык хәбәр ителә. Төнлә Блис елгасы районында артиллериядән атышу булган.

БЕРЛИН, 15 февраль. Германия информация бюросы хәбәр итә: „Фронтта патрульләрнең җанлы хәрәкәте күренде. Дошманның 16 кешелек удар группасының һөҗүмен Германиянең көчәйтелгән сакчылык посты кире какты. Германия патруле французларның күзәтү пунктын юк итте. Шул вакытта берничә солдат пленгә алынды“.

БЕРЛИН, 15 февраль. Германия информация бюросы хәбәр итә: „Кичә Германиянең хәрби диңгез көчләренең чаралары нәтиҗәсендә дошман барлыгы 58 мең тонна авырлыктагы берничә пароходын югалтты. Германия су асты көймәләренең уңышлы операцияләре Англия пароходларының нормаль йөрүен тәэмин итү өчен Англия тарафыннан үткәрелә торган чараларның нәтиҗәсез икәнлеген күрсәттеләр“.

ЛОНДОН, 15 февраль. Рейтер агентлыгы Англиянең 12.000 тонна авырлыгындагы „Султан Стар“ йөк пароходының батырылганлыгын хәбәр итә. Пароходның экипажы 70 кешедән торган. (ТАСС).

ГЕРИНГ РЕЧЕ

БЕРЛИН, 16 февраль. (ТАСС). Германиянең информация бюросы кичә Герингның радио буенча речь сөйләгәнлеген хәбәр итә. Аның рече Германия авыл хуҗалыгының якындагы бурычларына багышланган. Германиягә каршы Англиянең экономик блокадасының уңышсыз икәнлеген күрсәтеп, Геринг „Германияне экономик яктан да, сугыш ягыннан да җиңеп булмый“ дигән. Сугыш алдыннан ук инде Германиядә ашлык һәм башка продуктлар запасы хәзерләнгән булган. „Ләкин сугыш барышында без запасыбызга гына ышанып ята алмыйбыз“—дигән Геринг һәм продуктлар җитештерүне арттыру өчен мөмкин булганнарның бөтенесен эшләргә кирәклекне әйткән. Шулай ук ул чәчүне тәэмин итү өчен күп кенә авыл хуҗаларының армиядән отпуск алачакларын белдергән. Авыл хуҗалыгында хәзер эшләүче хәрби пленныйлардан тыш, Германиягә 1 миллионнан артык поляк авыл хуҗалыгы эшчеләре китереләчәк. Майлы культуралар чәчелә торган җирләрнең күләме кимендә 200 мең гектарга арттырылачак. Сөтчелек хуҗалыгын үстерү теләге белән сөт бәясе литрына 2 пфенг, ә май бәясе—кадагына 20 пфенг арттырылачак. Геринг үзенең речен „1940 нчы елны авыл хуҗалыгы сугышында“ уңышларга ирешүгә чакыру белән тәмам итте.

ШВЕЦИЯДӘ АНГЛИЯ ШПИОННАРЫН КУЛГА АЛУ

ОСЛО, 14 февраль. (ТАСС). „Афтенпостен“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Стокгольмда экономик шпионлыкта гаепләнеп Эрланд, Эдвард Линд, Вильямс Бич һәм маклер Янсон кулга алынганнар. Бич—Англиянең сабын кайнатучы „Сэнлайт“ тресты белән элемтә тотучы англичан.

БЕРЛИН, 16 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Швециядә кулга алынган өч кеше үзләренең Англия файдасына экономик шпионлык белән шөгыльләнгәнлекләрен икрар иткәннәр. Кулга алынганнар Швеция портларыннан руда җибәрү белән аеруча кызыксынганнар. Вильямс Бич балык тотучы булган булып күп тапкырлар Стокгольм тирәләренә барган.

СССР НЫҢ СЛОВАКИЯДӘГЕ ИЛЧЕСЕНЕҢ ПРЕЗИДЕНТ ТИСОГА ЫШАНЫЧ ГРАМОТАЛАРЫН ТАПШЫРУЫ

ПРАГА, 16 февраль. (ТАСС). 14 нче февральдә СССР ның Словакиядәге илчесе иптәш Пушкин Словакия республикасы президенты Тисо әфәндегә үзенең ышаныч грамоталарын тапшырды. Ышаныч грамоталарын тапшырганда Словакиянең чит ил эшләре министре Дурчанский, протоколлар бүлеге директоры Радлинский, чит ил эшләре министрлегенең башка работниклары, шулай ук СССР ның Словакиядәге илчелегенең бөтен составы катнаштылар. Словакия республикасы президенты Тисо әфәнде һәм СССР илчесе иптәш Пушкин котлау речьләре сөйләделәр. Ышаныч грамоталарын тапшырганнан соң иптәш Пушкинны Словакия республикасы президенты кабул итте. Кабул итүдә чит ил эшләре министре Дурчанский катнашты.

НОРВЕГИЯ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮГӘ КАРШЫ ЧЫГАЛАР

ОСЛО, 16 февраль. (ТАСС). „Арбейдерен“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 13 нче февральдә Люсекам шәһәренең кәгаз эшчеләре җыелышы сугыш куркынычы турындагы мәсьәләне тикшергән. Эшчеләр сугыш уты кабызучыларның Норвегияне сугышка тартырга маташуларын нык гаепләп резолюция кабул иткәннәр.

Бруммундал шәһәренең төзү эшчеләре союзының еллык җыелышында Норвегиянең реформист профсоюзлар берләшмәсе җитәкчелегенең ак Финляндия өчен эшчеләр туплау турындагы циркуляре тикшерелгән. Бу вербовкада катнашмаска дип бер тавыштан карар кабул ителгән.

Тофта шәһәрендә булган җыелышта Норвегия компартиясенең Үзәк Комитеты секретаре агымдагы политик момент турында доклад ясаган. Ул ак финнәр Совет дәүләтенә каршы һәм хезмәт иясе фин халкына каршы сугыш алып баралар,—дип күрсәткән. Дискуссия вактында маглүм социал-демократ Вильгельмсен җыелышта катнашучыларга коммунист ораторның чыгышына „протест йөзеннән“ җыелышны ташлап чыгарга такдим иткән. Аннан соң сөйләгән күп кенә ораторлар—социал-демократлар партиясенең шактый атаклы членнары—Вильгельмсеннең чыгышын бик нык гаепләгәннәр. Күп кенә ораторлар үзләренең речьләрендә социал-демократлар партиясе җитәкчелегенең политикасына каршы протест белдергәннәр.

Веннесла шәһәренең (Норвегиянең көньягында) социал-демократ яшьләр оешмасы ак финнәрнең „профсоюзлар берләшмәсе“ секретаре Лоулуконың докладын тыңлаудан баш тарткан. Ул Норвегиянең төрле шәһәрләрендә йөреп ак финнәргә ярдәм күрсәтергә чакыра икән. Яшьләр җыелышында ак Финляндия файдасына җыелышлар үткәрмәскә һәм акча җыймаска карар чыгарылган.

„Пер-Кюре“ кәгаз фабрикасы эшчеләренең җыелышы реакцион профбюрократларның якшәмбе көн Маннергейм Финляндиясе файдасына эшкә чыгарга такдим итүен кире каккан.

ГОЛЛАНДИЯДӘ КЫЙММӘТЧЕЛЕКНЕҢ ҮСҮЕ

БРЮССЕЛЬ, 17 февраль. (ТАСС). Фламанд газетасы „Стандард“ Голландиядән алынган хатны басып чыгарган, бу хатта сугыш нәтиҗәсендә хезмәт ияләренең хәле шактый начарланганлыгы күрсәтелә. Сугыш вактында Голландиядә тормыш бәясе 10 процентка арткан һәм тагын да артуда дәвам итә. Налоглар һәм дәүләт җыемнары шактый артканнар. Исәпләп чыгаруларга караганда, Голландиядә һәрбер сатып алучы үзенең сатып алган товарларына түләгәндә елына 50—60 гульден күләмендә өстәмә налог түли. Автобусларда һәм тимер юлда йөрү тарифы арттырылган. Икмәккә, ярмага, иткә, йомыркага, майга, бакалея товарларына, шикәргә, бәрәңгегә һәм башкаларга ваклап сату бәяләре күтәрелгән.

(Телеграммаларның дәвамы 4 нче биттә).

Иптәш Г. К. Орджоникидзе.

СЕРГО ОРДЖОНИКИДЗЕ БЕЛӘН МИНЕМ ОЧРАШУЛАРЫМ

Серго Орджоникидзе белән мин беренче тапкыр 1932 нче елны очраштым. Ул Макеевка металлургия заводына килде һәм домна цехында булды. Серго Орджоникидзе эшчеләр белән ягымлы итеп сөйләште, аларның сүзләрен тыңлады, киңәшләр бирде. Иптәш Орджоникидзе минем өч улымның да металлурглар икәнлеген белгәннән соң мине мактады. Мин озак вакытлар буена шушы очрашу тәэсире астында булдым.

Бер елдан иптәш Орджоникидзе заводта тагын булды. Ул елмаеп, минем үткән елны картрак булып күренгәнлегемне әйтте:

— Сез хәзер яшәргәнсез,—диде ул.

— Мине тормыш яшәртә,—дидем мин.

1934 нче елны мин бер вакытта да онытмам. Илебезнең күп кенә металлурглары белән берлектә мин партия һәм хөкүмәт җитәкчеләренең кабул итүендә катнаштым. Сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинны мин беренче тапкыр күрдем. Серго Орджоникидзе мине иптәш Сталин янына алып килде.

— Бу Коробов,—диде Серго—аның өч улы өчесе дә металлурглар.

Иосиф Виссарионович минем кулымны нык итеп кысты һәм ягымлы гына елмаеп:

— Шундый уллар тәрбияләгәнсең, молодец,—диде.

1935 нче елны иптәш Орджоникидзе белән мин ике тапкыр очраштым. Беренче тапкыр СССР Үзәк Башкарма Комитеты президиумы утырышында, бу утырышта миңа һәм олы улым Павелга орденнар тапшырылды. Серго кешеләрнең үсүләре белән горурланды, аларның уңышларына шатланды. Мин залга кергәч тә ул:

— Бу—Коробов. Хәзер улы керер,—диде.

Икенче тапкыр авыр промышленность наркоматы бинасында очраштым. Мин завод эше белән килгән идем һәм иптәш Орджоникидзене күрермен дип уйламаган идем. Очраклы рәвештә генә коридорда аның белән очраштым. Москвага хатыным белән бергә килүемне белгәч, Серго:

Иртәгә хатыныгыз белән минем квартирама килегез,—диде.

Минем кыюсызлануымны күреп ул:

— Шулай, иртәгә, кич сәгать алтыда,—дип кабатлады.

Ул көнне хатыным белән без кичергәннәрне язып аңлату кыен. Иптәш Орджоникидзе безне алырга автомобиль җибәрде. Без Кремльгә киттек. Иптәшләрчә сөйләшү дүрт сәгать дәвам итте. Иптәш Орджоникидзе тарафыннан күрсәтелгән ягымлылык һәм игтибар мине рухландырды.

1936 нчы елны улым Илья белән берлектә Нарком кабинетында кабул итүдә булдым. Орджоникидзе һәр вакыттагы кебек шат күңелле, ачык йөзле иде, ләкин эше бик тыгыз вакыт иде. Озак сөйләшергә туры килмәде, аны Кремльгә чакырдылар. Онтылмас Серго белән бу минем соңгы тапкыр очрашуым булды.

Орденлы *И. Коробов.*

Киров исемендәге Макеевка заводының домна цехының обер-мастеры, УССР Верховный Советы депутаты.

Макеевка, 16 февраль. ТАСС.

СЕРГО ОРДЖОНИКИДЗЕНЕҢ ХЕРСОНДА БУЛУЫ ТУРЫНДА МАТЕРИАЛЛАР

Херсон—илебездәге күп шәһәрләрнең берсе. Аның тарихы ялкынлы революционер Г. К. Орджоникидзе исеме белән бәйләнгән.

Серго Херсонда беренче тапкыр 1918 нче елның февралендә булган. Урыннардагы архивларда саклана торган тарихи документлар, Орджоникидзенең төньяк губерналардагы эшчеләргә азык ярдәме оештыру турында Ленин һәм Сталин заданиеләрен бик яхшы үтәгәнлеген күрсәтәләр.

Ул чагында иптәш Орджоникидзе крестьян депутатлары Советларының һәм җир комитетларының Херсон губерна съезды эшендә катнашып, меньшевиклар һәм эсерларны идея ягыннан тар-мар итүдә Херсон губернасындагы большевистик оешмаларга бик зур ярдәм итте. Аның бу съездда сөйләгән дәртле рече эсерлар тарафыннан хәзерләнгән резолюцияләрнең җимерелүләренә һәм большевистик резолюцияләрне кабул итүгә булышлык күрсәтте.

Иптәш Орджоникидзе Херсонда икенче тапкыр 1929 нчы елны булды.

Херсон хезмәт ияләре Ленинның һәм Сталинның турылыклы шәкертен искә алалар. Шәһәр революция музеенең Серго Орджоникидзе тормышына һәм эшенә багышланган күргәзмәсен һәр көнне меңнәрчә кешеләр карый. Серго Орджоникидзенең үлүенә 3 ел тулу көненә карата күргәзмә яңа экспонатлар белән тулыландырылды.

Херсон, 16 февраль. ТАСС.

Отчет-сайлау җыелышларында большевистик тәнкыйтьне тагын да җәелдерик

ЯҢА ПАРТОЕШМАДА

Бюро секретаре иптәш Захаров булган партоешмада отчет-сайлау җыелышы ике көн дәвам итте. Бу партоешма әле яшь: бары тик 7 айлык эшнең йомгагын тикшерә. Шушы кыска вакыт эчендә дә партоешма күп эшләр башкарган.

Бу коллектив алдына гаять зур бурыч куелган иде. Партия оешмасы бу бурычны намус белән үтәү өчен көрәшкә коммунистларны һәм бөтен коллективны туплауга, аңа дөрес житәкчелекне тәэмин итүгә төп игтибарны юнәлдергән.

Партбюро секретаре иптәш Захаров отчет докладында әнә шул турыда сөйләде. Докладта партбюроның һәм гомумән оешманың эшендәге кимчелекләр большевикларча кыюлык белән тәнкыйть ителде. Коммунистлар отчет докладын зур активлык белән тикшерделәр. Бу хәл коллектив алдына куелган бурычларны үтәү өчен коммунистларның нык тупланган булуларын тагын да бер тапкыр күрсәтте.

Доклад буенча сөйләүчеләрдән Туловский, Уразманов, Прилепский, Михайлов һәм башка иптәшләр партия оешмасының үсеше һич тә канәгатьләнерлек түгеллеген әйттеләр. Отчет чорында бу оешмада партия сафларына бары 9 гына кеше кабул ителгән. Ә партия сафларын үстерү өчен коллективта резерв зур. Йөзләрчә комсомолецлар, Ватан эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы инженерлар, техниклар, стахановчылар һәм ударниклар бик күп. Ләкин партбюро бу кешеләрнең ничек үсүләре белән, аларның үз өсләрендә ничек эшләүләре белән тиешенчә кызыксынмаган.

Аннан соң Подвойский, Локалин һәм башка иптәшләр партбюро эшендәге төп кимчелекләрнең берсе итеп, партия пропагандасы эшенең йомшак торышын күрсәттеләр. Оешмадагы коммунистларның күпчелеге „Кыскача курс“ның III нче һәм IV нче бүлекләрен генә өйрәнәләр әле. Күп кенә комсомолецлар партия тарихын өйрәнү эшенә керешмәгәннәр.

— Бездә массовый агитация эшендә,—ди иптәш Локалин,—кампаниячелек бар. Бер вакыт, коллективка җаваплы бер задание бирелде. Бу заданиене үтәү өчен көрәшкә партия оешмасы бөтен коллективны туплады һәм массовый агитация эшен дә шул бурычны үтәү өчен көрәшкә юнәлдерде. Нәтиҗәдә коллектив бу заданиене уңышлы үтәде. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлау кампаниясендә партия оешмасы җидди сынау үтте. Бу вакытта безнең оешма партияле һәм партиясез большевиклардан талантлы агитаторлар һәм оештыручылар тәрбияләде.

Җыелышта сөйләүчеләр партбюроның күп кенә башка җитешсезлекләре булганлыгын әйттеләр һәм аларны бетерү өчен эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

Җыелыш партбюроның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Партбюроның яңа составын һәм район конференциясенә делегатлар сайлады.

Габитов.

Юдино станциясендә коммунистларның отчет-сайлау җыелышы. РӘСЕМДӘ: партбюро эше турында бюро секретаре иптәш Послетаев отчет ясый.
В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ПАРТКОМ ҺӘМ ҮТӘЛМӘГӘН КАРАРЛАР

16 нчы февральдә Серго Орджоникидзе исемендәге завод партоешмасының отчет-сайлау җыелышы башланды.

Партком секретаре иптәш Забродченко башта оешманың уңышлы эшләренә тукталды. Отчет чорында партия оешмасы 45 процентка үскән. Агитация-масса эшләре буенча да шактый эшләр башкарылган. Күп кенә коммунистлар һәм партиясез большевиклар үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә зур тырышлык күрсәтәләр.

Докладчы шулай ук парткомның эшендәге җитешсезлекләрне дә әйтергә тырышты. Ләкин ул җитешсезлекләр турында күбрәк гомуми сүзләр белән генә чикләнде. Доклад буенча фикер алышуларда катнашучылар парткомның эшендәге күп кенә җитешсезлекләрне ачтылар.

Иптәш Будников үзенең чыгышында болай диде:

— Цехлардагы агитация эшенең барышы турында парткомга мәгълүмат кирәк булган булса кирәк. Партком члены иптәш Тихомиров кителмәгәндә безнең цехка килде. Ул цех начальнигының кабинетына кереп бикләнде дә, цех партоешмасының секретарен табып китерергә кушты. Секретарь килгәч, аңардан агитация эшенең барышы турында 2 минут эчендә мәгълүмат бирүне таләп итте. Менә шуннан соң 3 ай вакыт узды инде, цехка Тихомиров та һәм парткомның башка членнары да килгәннәре юк. Партком һәм аның членнары цехларның тормышы, план үтәлеше һәм цех партоешмаларының практик эшләре белән бик аз кызыксыналар.

Күп кенә коммунистлар парткомның эш практикасындагы яраксыз стильне нык кына тәнкыйтьләп чыктылар.

—Партком секретарьлары Мальцев һәм Аникин иптәшләр янына эш белән керсәң,—ди иптәш Сушков,—бер генә мәсьәләне дә ахрына кадәр хәл итеп булмый. Коммунистлар партком секретарьлары яныннан, аларның эш практикасыннан риза булмый чыгалар. Шуңа күрә күп кенә иптәшләр турыдан-туры райкомга барып, мәсьәләне анда хәл итеп кайтулары бер дә гаҗәп нәрсә түгел.

Комсомолның завод комитеты секретаре иптәш Соколов партком җитәкчеләре комсомол оешмасына системалы рәвештә җитәкчелек итмәүләре турында сөйләде. Партком бу отчет чорында комсомол оешмасының эше турында бары тик бер генә тапкыр доклад тыңлаган, ә доклад буенча чыгарылган карар үтәлми калган.

Сөйләүчеләрнең күпчелеге кабул ителгән карарларның үтәлеше өчен парткомның ныклы көрәш алып бармавын күрсәтеп үтте. Отчет чорында партком партиянең эчке эшләре буенча 11 карар чыгарган. Шулардан бер карарның гына үтәлеше тикшерелгән. Партком моннан 4 ай элек агитация-масса эшләренең торышы турында цех партбюро секретарьлары Чернов һәм Гоголев иптәшләрнең докладларын тыңлаган. Ә карарның үтәлеше бер тапкыр да тикшерелмәгән.

Тагын менә массовый оборона эше турында кабул ителгән карарны алырга мөмкин. Бу карарның чыгарылганына 3 айдан артык вакыт үткән. Заводта массовый оборона эшләрен оештыру өчен җаваплылык партком члены иптәш Родинга йөкләнгән. Ә ул берничә ай озак сроклы командировкаларда булган. Партком аңа ышанып, бу эшне бөтенләй үз агымына куйган, карар үтәлмәгән.

Цехлардагы һәм бүлекләрдәге татар эшчеләре арасында политик-масса эшләрен татар телендә алып баруның начар торуы турында узган отчет-сайлау җыелышында нык кына әйтелгән иде. Бу турыда парткомның махсус карары да булды, ләкин эш һаман да артык яхшырмады. Иптәш Фарзан бу эштәге җитешсезлекләрне күрсәтте.

Доклад буенча барлыгы 20 дән артык кеше чыгып сөйләде. Күрсәтелгән тәкъдимнәрдән чыгып җыелыш отчет докладь буенча карар кабул итте. Парткомның эше канәгатьләнмәслек дип табылды.

Г. Миңнул.

ҖЫЕЛЫШ ЗУР ОЕШКАНЛЫК БЕЛӘН ҮТТЕ

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру нигезендә Наркомфин партоешмасы отчет чоры эчендә шактый уңышларга ирешкән. Партоешма төп профессиядә эшләүчеләр исәбенә 18 кешегә үскән, производствода коммунистларның авангардлык рольләре шактый күтәрелгән. Верховный Советларга һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар кампанияләре вактында партоешма коммунистларның актив катнашуларына ирешкән. Партияле һәм партиясез большевикларның идея-политик белем дәрәҗәләрен күтәрү буенча да күзгә күренерлек эшләр бар. Наркоматтагы барлык 167 сотрудникның 137 се „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнү бу нәрсәне ачык күрсәтә. „Кыскача курс“ның 7—10 бүлекләрен өйрәнүче иптәшләр дә бар. Болар рәтенә Төхватуллин, Азизов, Аюпов, Яковлев, Гусев, Байбурин иптәшләрне кертергә мөмкин.

Ләкин партоешманың практик эшендә күп кенә җидди кимчелекләр булганлыгы җыелыш барышында бик ачык күренде. Кадрларны тәрбияләү, аларның идея-политик белемнәрен күтәрү өлкәсендә партоешманың җитешсезлекләре күп әле. „Кыскача курс“ның чыгуына бер ел ярым вакыт үтүгә карамастан, партия тарихын өйрәнүче иптәшләрнең күпчелеге 2—3 нче бүлекләрне генә өйрәнәләр. Үзләренең политик артталыкларын бетерү эшенә гамьсез караучы Ихсанов, Димитриев, Хопаев кебек коммунистлар да бар. ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә партбюро тиешле булышлык оештырмаган һәм контрольлек итмәгән.

Партиягә яңа кабул ителгән коммунистлар белән политик тәрбия эше алып баруда, җаваплы эшләргә күтәрелгән яшь кадрлар белән системалы эш алып баруда, аларга практик ярдәм итүдә партбюроның йомшак эшләгәнен доклад буенча сөйләүче барлык иптәшләр күрсәтеп уздылар. Социалистик ярышка җитәкчелек итүдә, массовый оборона эшләрен бүгенге көннең сорауларына җавап бирерлек итеп оештыруда, Наркомфин аппаратында һәм аның системасында волокита, бюрократлык элементларына каршы көрәштә партбюроның эшләгән эше һич тә канәгатьләнерлек түгел. Большевистик тәнкыйтьне җәелдерүдә, социалистик ярышны оештыруда стена газеталарының роле гаять зур. Ләкин наркоматның стена газетасы бу мәсьәләләрне тиешенчә яктыртмый. Отчет-сайлау җыелышына карата чыгарылган номерында да тәнкыйть мәсьәләләре тиешле югарылыкка күтәрелмәгән, социалистик ярыш турында булган мәкаләдә бер генә конкрет факт та күрсәтелмәгән.

Шушындый җидди кимчелекләр булуга карамастан, партбюро секретаре иптәш Ибраһимов үзенең отчет докладында уңышларга күбрәк тукталды, җитешсезлекләрне ачып салуга саранлык күрсәтте. Доклад буенча чыгып сөйләүче иптәшләр докладчы тарафыннан „онытылып“ калынган күп моментларын өстәделәр, докладчының хәтеренә төшерделәр. Ләкин шуны әйтергә кирәк, җыелышның беренче көнендә тәнкыйть мәсьәләсе сүлпән барды, бары тик икенче көнне генә көчәйде, доклад буенча сөйләүчеләр партбюроның эшендә булган җидди кимчелекләрне конкрет рәвештә күрсәттеләр.

Җыелыш оешканлык белән үтте. Беренче һәм икенче көнне җыелышка килергә тиешле булган барлык коммунистлар бер минутка да кичекмәстән үз вактында килеп җиттеләр. Җыелышта 35 коммунистның 20 се доклад буенча фикер алышуларда катнашты һәм бик күп эшлекле тәкъдимнәр кертелде. Җыелыш партбюроның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Бюро составына Шәрәфиев, Ибраһимов, Азизов, Асеева, Мостафин, Иван Михайлов һәм Чванов иптәшләр сайландылар. ВКП(б) ның Бауман район конференциясенә 4 делегат сайланды.

Баязитов.

БОЛЬШЕВИСТИК ТӘНКЫЙТЬ

Наркомат партоешмасының үзенчәлеге бар. Устав моны үтә ачыклык белән әйтә һәм шуның нигезендә конкрет бурычлар куя.

— Аппаратны яхшырту, теге яки бу кимчелекләр турында үз вактында сигнал бирү.

Татнаркомзем партоешмасының отчет-сайлау җыелышы партбюродан шушы бурычларның ничек үтәлүе турында сорады. Фикер алышуларга катнашучыларның күпчелеге бюроның бу бурычларны үти алмаганлыгын әйтте, тәнкыйть итте.

Ике утырыш буена дәвам иткән фикер алышулар бер нәтиҗәгә:

— Бюроның практик эше канәгатьләнерлек түгел, дигән нәтиҗәгә кайтып калды. Һәм җыелыш партбюро эшенә шундый бәя бирде.

Антонов, Косушкин, Пермяков, Гаврилов, Черзор һәм башка иптәшләр партбюроның Наркомзем аппараты кебек зур учреждениене яңа баштан кору эшендә читтә торуын әйттеләр.

Бюро яңа төзелгән производство-территориаль управлениеләрнең штат мәсьәләләре белән дә кызыксынмаган, наркомат җитәкчелегенә булышлык итмәгән.

Иптәш Ягфаров бюроның ялгышлыклары, партия укулары эшен оештыра белмәве турында менә нинди фактларга тукталды. Бер заман бюро ике түгәрәк төзергә керешә. Берсе „карт коммунистлар“ өчен (!), икенчесе „яшьләр“ өчен. Күптән түгел үткән теоретик конференция, беседа ясауга әйләнү белән тәмам булган. Чөнки докладчы иптәш Соколовтан башка бер кеше дә укып килмәгән.

— Беседаны „җанландыру“ өчен конференцияне өч көнгә кичектерделәр. Миңа хәзерләнеп килергә куштылар. Өченче көнне мин хәзерләнеп килдем, ләкин докладчы үзе килмәгән иде, ди иптәш Ягфаров. Ул конференция белән көлкегә калу турында барсы да сөйләде. Ләкин ул көлке түгел, бәлки аяныч факт.

Иптәш Мишаков: „ел ярым эчендә бюрода 4 секретарь алмашынды, бюро утырышында бер кайчан да тулы состав булмады, 7 членның 3—4 се катнаша иде, ә хәзер икәү генә утыра башладык“ ди.

— Партиягә яңа алынган 35 коммунист, аппаратка күтәрелгән 60 лап яңа кадрлар нәрсә эшлиләр, ничек яшиләр?

Бюроның моны белмәве, алар белән эшләмәве турында да сөйләделәр. Бюро аппаратны өйрәнми, белми. Биек түшәмле зур бинада, катлаулы аппаратта эшләүче кешеләрнең тулай оркестры нәрсә уйнаганны ишетми. Иске бюроның бәласе шунда.

Кичә җыелыш бюроның яңа составын сайлады. *ф. Балыкчы.*

ОЕШМАГА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ САЙЛАНДЫ

Лаиш районының Рождественский МТС ы янындагы партоешмада отчет-сайлау җыелышы зур активлык белән үтте. Фикер алышуларда катнашучылар оешма секретаре иптәш Алексеевның эшен кискен рәвештә тәнкыйтьләделәр. Партия оешмасының акрын үсүе аеруча күрсәтелеп үтелде. Отчет чоры эчендә бары 4 кеше партия сафларына кабул ителгән.

Җыелыш яшерен тавыш бирү тәртибендә оешма секретаре итеп иптәш Архиповны сайлады.

ТӘНКЫЙТЬ ЙОМШАК БУЛДЫ

Чаллы районының башлангыч партоешмаларында отчет-сайлау җыелышлары башланды. Беренче көн райондагы кайбер оешмаларда җыелышларның түбән дәрәҗәдә үтүен күрсәтте.

Чаллы МТС ы янындагы партоешма секретаре иптәш Никитина үзенең отчет докладында оешма эшендәге һәм МТС дирекциясе эшендәге җидди кимчелекләрне ачып салмады.

Чаллы МТС ының начар эшләвен районда һәр кем белә. Ул узган ел да үзенең бурычларын үтәмәде, быел да язгы чәчүгә ныклы хәзерлек алып бармый, 57 тракторның бары 34 енә генә ремонт ясалган. МТС кадрлар белән тәэмин ителмәгән.

Агитаторлар арасында планлы эш алып барылмаган. Коммунист агитаторлардан Хисаметдинов, Курочкин һәм Ханнанов иптәшләр җирле Советларга сайлаулардан соң бер беседа да үткәрмәгәннәр. Җыелышта, партия тарихын коммунистларның ничек өйрәнүләре турындагы мәсьәлә күтәрелде. Никитина һәм Яһудин иптәшләрдән башка бер коммунистның да ВКП(б) тарихын өйрәнмәве беленде.

Секретарьның отчет докладыннан соң райком вәкиле иптәш Хрулев чыгыш ясады. Ләкин ул да партоешма эшендә булган кимчелекләрне күрсәтмәде. Докладчы һәм чыгып сөйләүчеләр партиянең XVIII нче съезды карарларын һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының соңгы пленумы карарларын оешманың ничек тормышка үткәрүенә бөтенләй тукталмадылар.

(ТатТАСС).

БЕЗНЕҢ ПАРТОЕШМА КЕМНӘР ХИСАБЫНА ҮСӘ

Казан Пехота училищесенең курсантлары һәм начальниклар составы арасында ВКП(б) сафларына керергә теләүчеләр саны соңгы вакытларда аеруча нык үсте. Хәзер партоешманың бер генә җыелышында да партиягә кабул итү мәсьәләсе каралмыйча калмый диярлек мөмкин. Соңгы ике ай эчендә партоешма (секретаре иптәш Глобин) 31 процент үсте.

Моның сере нәрсәдә соң? Барыннан да элек, партия-масса һәм пропаганда эшләренең яхшы куелуында. Большевиклар партиясенең узгандагы героик көрәше турында, җиңелүне белми торган Ленин—Сталин партиясе турында курсантлар һәм начальниклар составы арасында системалы рәвештә беседалар үткәрелә. Җыелышларда докладлар куела. Политик-масса һәм пропаганда эшләре иптәш Сталинның тууына 60 ел тулуга хәзерлек һәм аны үткәрү чорында, Ленинның үлүенә 16 ел тулу көннәрендә аеруча киң җәелдерелде.

Партиянең һәм Совет хөкүмәтенең политикасы белән, халыкара хәл мәсьәләләре белән яхшы таныш булу нәтиҗәсендә, курсантларда, командирларда һәм политработникларда партия сафларына керү теләге гаять зур. Иптәш Үтяшев үзенең гаризасында болай дип яза: „Партоешмадан мине ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алуны сорыйм. Үземне безнең партиябезнең сафларына керергә тулы хәзерләнгән дип саныйм. Партиянең барлык карарларын большевикларча, устав таләп иткәнчә үтәрмен. Ватан эше өчен көрәштә ВКП(б) члены дигән бөек исемне намус белән акларга сүз бирәм“.

Менә иптәш Иванов гаризасы: „Партоешмадан минем гаризамны карауны һәм мине коммунистлар партиясе сафларына кандидат итеп алуны сорыйм. Мин, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин тәгълиматларын намус белән, тырышып өйрәнермен һәм массаларга өйрәтермен. Ленин—Сталин партиясе эшенә бөтенләйгә бирелгән хәлдә мин, партиянең беренче чакыруы буенча, социалистик Ватаныбызны саклау өчен алгы сафларда барырмын һәм сугышчыларны алып барырмын. Әгәр дә кирәк булса, пролетар революция казанышларын саклау өчен канымны һәм тормышымны да бирермен“.

Югарыда күрсәтелгән бу гаризаларда безнең барлык сугышчыларыбызның һәм командирларыбызның теләкләре һәм фикерләре әйтелгән.

Безнең партоешманың кемнәр хисабына үсүен күрсәтеп үтү бик әһәмиятле. Менә шушы көннәрдә генә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алынган иптәш Тихонов. Аның атасы тимер юлда машинист булып эшләгән вактында, производстводан аерылмыйча, зур тырышлык белән укып инженер булып чыккан. Иптәш Тихонов атасындагы бу гүзәл сыйфатларны нык үзләштергән. Ул укуда зур тырышлык күрсәтә. Барлык хәрби дисциплиналар буенча отлично укый. Иң яхшы дисциплиналы, тотнаклы курсантлардан санала. Курсантлар һәм комсостав каршында зур авторитет белән файдалана. Шуңа күрә подразделение командованиесе иптәш Тихоновны командирлык постына күтәрде һәм ул кече командирларның иң үрнәклеләреннән берсе булып танылды.

Иптәш Чуканов күптән түгел кандидатлыктан ВКП(б) члены итеп кабул ителде. Ул, хәрби һәм политик хәзерлек буенча отличник булу белән бергә, партия-масса эше алып бара. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлау кампаниясе вактында Казан Шәһәр Советына сайлаулар буенча округ комиссиясе секретаре булып эшләде һәм иң яхшы эшләүчеләрдән саналды. Хәзер ул комсомол оешмасының пленум члены һәм политрук ярдәмчесе булып эшли.

Менә иптәш Гульян. Ул училищедә үзен үрнәкле һәм яхшы курсант итеп танытты. Хәрби һәм политик хәзерлек буенча яхшы күрсәткечләргә иреште. Шуңа күрә командование аңа рәхмәт белдерде.

ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Усовны алыйк. Ул шулай ук хәрби һәм политик хәзерлек буенча отличник. Курсантлар һәм командирлар арасында зур авторитет белән файдалана.

Безнең партоешма тарафыннан партиягә алынучылар турында мондый гүзәл мисальләрне күп китерергә мөмкин. Ләкин шушы китерелгән мисальләр дә безнең партоешманың сафлары иң яхшы кешеләр—социалистик Ватанга, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләр хисабына үскәнлеген бик ачык күрсәтәләр.

Хәзер, барлык совет халкы данлыклы Кызыл Армиянең XXII еллыгына хәзерләнә һәм аны яңа уңышлар белән билгеләп үтү өчен көрәшә. Бу данлыклы XXII еллыкны каршылау унае белән, безнең партоешма коммунистларның, комсомолецларның авангардлык рольләрен тагын да югары күтәрер, кадрларны марксизм-ленинизм тәгълиматы белән коралландыру эшен тагын да яхшыртыр һәм үзенең сафларын иң алдынгы кешеләр хисабына тагын да үстерүне тәэмин итәр.

Ив. Гостев.
Батальон комиссары.

КАРАР КАБУЛ ИТМИЧӘ БЮРО САЙЛАДЫЛАР

15 нче февральдә Теләче районында ВКП(б) райкомы һәм район башкарма комитеты янындагы башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары булды.

ВКП(б) райкомы янындагы оешмада партбюро секретаре иптәш Москвин доклад ясады.

Отчет докладь буенча фикер алышуларда 12 кеше чыгыш ясады. Иптәш Шәймөхәметов үзенең чыгышында болай диде:

— Безнең оешма башка оешмаларга үрнәк булып торырга тиеш. Ләкин безнең моңа ирешә алганыбыз юк әле. Коммунистлар арасында тәрбия эшләре йомшак куелган. Декабрь аенда партия җыелышлары булмады. Январьда һичбер хәзерлексез бер җыелыш үткәрелде. Партия җыелышларының карарлары үтәлми.

Җыелыш партбюроның яшь коммунистларны тәрбияләү өлкәсендә йомшак эшләвен кискен рәвештә тәнкыйтьләде. Аларга поручениеләр бирелми. Бирелгәннәренең үтәлеше тикшерелми. Мәсәлән, яшь коммунист иптәш Хәлиловага комсомол мәктәбендәге политграмота түгәрәгенә җитәкчелек итү тапшырылган иде. Ул бу поручениене үтәмәде. Ә партбюро аның эше белән кызыксынмады.

Райком работниклары учетта торган оешмада отчет-сайлау җыелышы үрнәк рәвештә үтәргә тиеш иде, ләкин ул алай булмады. Җыелыш тиешенчә хәзерләнелмәгән иде. Отчет докладын тикшергәннән соң берәү дә карар проекты кертә алмады. Шунлыктан җыелыш бер төрле дә карар кабул итмәде. Шуңа да карамастан партбюрога членнар сайлау үткәрелде. Җыелышны ачу алдыннан коммунистларның партдокументлары тикшерелмәде. Яшерен тавыш бирү өчен бюллетеннәр өләшү вактында гына ВКП(б) члены иптәш Галәветдиновның партбилеты өйдә калганлыгы беленде.

(ТатТАСС).

ГРИГОРИЙ КОНСТАНТИНОВИЧ ОРДЖОНИКИДЗЕ

(ҮЛҮЕНӘ 3 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА)

ИПТӘШ СЕРГО—ПРОЛЕТАР ПОЛКОВОДЕЦ

Иптәш Орджоникидзенең хәрби эше Бөек Октябрь Социалистик революциясенең беренче көннәреннән үк, Царское Село һәм Пулково янында башланды. Ул көннәрдә Керенский һәм генерал Краснов үзләре тарафыннан алданган солдатларны кызыл Питерга һөҗүмгә алып баралар иде. Ленин һәм Сталин Серго Орджоникидзене фронтка җибәрделәр. Ул һич тә курыкмыйча дошманнар өстенә ташланды һәм Краснов самокатчыларын революциягә каршы чыкмаска, бәлки революцияне яклап чыгарга кирәклеккә оста рәвештә ышандырды. Иптәш Серго тарафыннан масса арасына алып киленгән дөреслек җинде: самокатчылар кулларына корал тотып, Совет властен яклап чыктылар.

Революцион Питер өстенә куркынычлы яңа дошман—ачлык килә башлады. Ленин һәм Сталин иптәш Орджоникидзене Украина районына вакытлы, гадәттән тыш комиссар итеп билгеләделәр. Аңа бик җаваплы задание бирделәр: Ул пролетар үзәкләрне икмәк белән тәэмин итәргә тиеш булды. Иптәш Орджоникидзенең азык өлкәсендәге эшенә Ленин югары бәя бирде. Ул Харьковка: „...Азык буенча күргән энергияле чараларыгыз өчен чын күңелемнән рәхмәт әйтәм... Бөтен өмет Сездә...“ дип телеграмма җибәрде.

Партия иптәш Сергоны бер фронттан икенчесенә күчереп торды.

Ул большевистик крепостьны—Царицынны саклаган героик көннәрдә бөек Сталинның иң якын ярдәмчесе булды.

Бер вакытны ак бандитларга каршы сугышның иң кызу барган вакытында кызыллар түзә алмадылар һәм чигенә башладылар. Шул чагында ут линиясенә иптәш Серго килеп чыкты. Ул:

— Минем арттан, атакага!—дип команда бирде һәм кулына маузер тотып, беренче булып акларның позицияләренә һөҗүм башлады. Кызыл армеецлар „ура“ кычкырып аның артыннан бардылар. Аклар каушадылар һәм берничә минуттан паникалы рәвештә кача башладылар.

1918 нче елның язында иптәш Серго Россиянең көньягына гадәттән тыш комиссар итеп билгеләнде. Ул Терекка китте һәм бер ел буена Төньяк Кавказда торды. Ул анда Октябрь казанышларын ныгытуда һәм революция дошманнарын юк итүдә ярдәм итте. Ул тау халыкларын һәм хезмәтчел казакларны сугышка алып барды. Ул Теректа эсер Бичераховның ак казаклар отрядларына каршы унышлы көрәш алып барды. Владикавказ янында генерал Деникин армиясенә каршы бик каты сугышты. Серго җитәкчелегендәге 11 нче героик Кызыл Армия, Деникинның үзенен икрар итүенчә, Кубаньдагы һәм Теректагы сугышларда 30 мең ак гвардеецны юк итте.

1919 нчы елның июленнән алып иптәш Орджоникидзе турыдан-туры иптәш Сталин җитәкчелегендә 16 нчы армия Реввоенсоветында эшләде. Ул белорус халкына поляк паннары изүеннән котылуда ярдәм итте. Гражданнар сугышы тарихына кереп калган һәм бер кайчан да онтылмаслык бик күп героик эпизодлардан берсендә—Серго кулына винтовка тотып, сазламыклы урман аркылы төнлә белән Борисов шәһәренә бара, анда ак поляклар частьләренең ничек урнашканлыкларын өйрәнә, һәм соңыннан кискен штурм ясап, шәһәрне дошманнан чистарта.

Шул ук елның көзендә, аклар бөтен көчләре белән Москвага таба килгәндә, Деникинны туздыру эшенә җитәкчелек итүгә иптәш Сталин куелды. Көньяк фронтның хәл иткеч участкысына иптәш Сталин үзенең турылыклы иптәше һәм дусты иптәш Сергоны куйды. Ул 14 нче армиянең Реввоенсовет члены итеп билгеләнде. Г. К. Орджоникидзе, үзенең куркусыз, ялкынлы большевик полководецлык үрнәге белән кызыл армеецларны, эшчеләрне һәм крестьяннәрне рухландырды.

Иптәш Сталинның „Орелны алырга“ дигән директивасы турыдан-туры Г. К. Орджоникидзе җитәкчелегендә үтәлде. Монда аклар үзләренең иң яхшы, иң ышанычлы частьләрен—Корниловның, Марковның, Дроздовның офицерлар полкларын туплаганнар иде. Кызылларның Серго җитәкчелегендәге удар группасы баштан аяк коралланган деникинчыларны качарга мәҗбүр итте.

Иптәш Серго хезмәтчел халык белән якын элемтә тотуны бер генә минутка да өзмәде. Эшчеләр һәм крестьяннәр, сугышчылар һәм командирлар үзләренен бу шат күңелле һәм куркусыз, үткен сүзле һәм эчкерсез, бөек һәм гади юлбашчысын һәм җитәкчесен яраттылар.

1920 нче елның апрель ае ахрында Кызыл Армиянең Орджоникидзе һәм Киров җитәкчелегендәге батыр полклары пролетар Бакуга килеп керделәр, ә 10 айдан соң иптәш Серго Ленинга һәм Сталинга тәэсирле телеграмма җибәрде: „Тифлис өстендә Совет властеның кызыл байрагы җилферди. Яшәсен Советлар Грузиясе!“.

* * *

Безнең көннәрдә, канлы палач Маннергейм властеннан азат булуда фин халкына ярдәм итеп, героик Кызыл Армия ак финнәргә каршы көрәш алып барганда, һәрбер командир алдына, һәрбер сугышчыбыз алдына пролетар полководец Серго Орджоникидзенең бөек образы килеп баса. Куркусыз большевик — Ленинче Григорий Константинович Орджоникидзенең героик эшләре миллионнар өчен үрнәк булып хезмәт итәр.

В. Черкасский.

Серго һәм авыл хуҗалыгын машиналаштыру

Владимир Ильич Ленин болай дип хыялланган иде: „...безнең, фигуралы итеп әйткәндә, бер аттан икенчесенә, ягъни крестьян, мужик атыннан, хәерчеләнгән аттан, бөлгән крестьян иленә чамаланган экономика атыннан,—эре машина индустриясе атына, электрификация, Волховстрой һ. б. атына, пролетариат үзенә эзли торган һәм эзләми кала алмый торган атка күчеп утырырга хәлебездән киләчәк“ (Ленин. Әсәрләр, том XXVII, бит 417).

Бу хыял тормышка ашырылды. Лениннең бөек дусты һәм аның эшен дәвам иттерүче Сталин илне Днепрогэс һәм Азовсталь, Магнитка һәм Кузнецк, транспорт һәм комбайн заводлары атына күчереп утыртты. Бу гаять зур, героик эшкә авыр промышленность халык комиссары, „индустрия маршалы“, „стахановчылар командармы“ Серго җитәкчелек итте.

Сталинград трактор заводын эшкә башлату искә төшә. Завод өзеклек белән эшли иде. Тракторлар эшләп чыгаруны тәртипкә салу өчен булган омтылышлар берсе дә нәтиҗә бирмәде. Заводта эш көчләре алмашынып торды, кешеләрнең урнаштырылулары һәм производствоның оештырылуы начар иде.

1931 нче елның апрелендә заводка Серго килде.

Серго барлык цехларны тикшереп чыкты, эшчеләр һәм инженерлар белән сөйләште; дөньяда иң яхшы җиһазлары булган заводның ни өчен артта калганлыгын сорашты. Берәү дә ачык җавап бирә алмады. Җыючылар гаепне коючылар өстенә, тимерчеләр—хәзерләүчеләр һәм инструментальщиклар өстенә аудардылар.

„Цехлардан берсендә бер эшче аңа өндәште:

— Туктагыз әле!

Серго туктады. Эшче анардан:

— Иптәш, син ВСНХ дан буласыңмы?—дип сорады.

— Әйе,—диде Серго.

— Тәртип урнаштырырга приказ бир әле. Конвейерны кем теләсә шул җибәрә. Менә кара.

Конвейер тик тора иде. Ләкин кинәт конвейерны җибәрү кнопкасы янына бер яшь кеше йөгереп килә һәм тирә-якка карамыйча, кнопканы баса. Кайдадыр тимер яңгырый, инструментлар идәнгә коелалар. Конвейерда тыныч кына утыручы кешеләр кырыйга авып төшәләр.

—Һәр вакыт шулай,—ди эшче, Сергога карап,—кем тели, шул әйтми-нитми җибәрә. Шунлыктан авария була.

Серго конвейерны җибәрүче кешене чакырып ала.

— Син ни өчен кнопканы бастың?

— Нигә? Конвейер эшләргә тиеш бит.

— Син кем?

— Редакция сотрудникы...

Серго конвейер янында ике сәгатькә якын торды. Ул кайбер эшчеләрнең һәм белгечләрнең оста итеп, уйлап эшләүләрен, аерым детальләрдән әзер машинаның җыелуын игтибар белән күзәтүләрен карады. „Моны,—ди Серго,—ата үзенең беренче баласы тууны көткән картина белән чагыштырырга мөмкин. Хатыны бала тудыра, ә ул борчыла: әле шатлана, әле курка. Эшче нак менә шундый кыяфәт белән басып тора, конвейерга карый һәм анардан тракторның кайчан килеп чыгуын күзәтә“.

Серго заводның эше белән берничә көннәр танышты. Ул җитәкчеләргә: „Мин сездә күргәннәр—алар темп түгел, бәлки ыгы-зыгы килү генә“ диде.

Серго тимерчелек цехының ашханәсенә керә һәм беренче очраган эшчегә карап:

— Ничек ашаталар?—дип сорый.

Эшче кесәсеннән сынык агач кашык чыгара:

— Менә, ашап кара...

Ашның сыйфаты начар иде.

Серго:

— Нигә сез сынык кашык белән ашыйсыз?—дип сорый.

Эшченең ачуы килде:

— Кашык бирмиләр, өйдән алып килергә туры килә, ә бер каян да кашык табып булмый.

Берничә көннән завод коллективы җыелышында Серго зур речь белән чыкты. Җәйге клуб халык белән шыгырым тулган иде. Клубның ишеген ваттылар, шулай да йөзләрчә кешеләр эчкә керә алмадылар.

Серго бер сәгатькә якын сөйләде. Ул, хәзер завод тора торган урында, моннан 12 ел элек шундый заводлар төзү өчен каты сугыш барганлыкны искә алды. Йөзләрчә большевиклар монда үзләренең башларын югалттылар. Һәм менә хәзер, бөтен ил завод коллективыннан тракторлар көткәндә, завод тракторлар бирми.

— Эш нәрсәдә?—дип сорый Серго.—Сездә кешеләр яхшы, машиналар яхшы, ә тракторлар юк... Сезнең комсомолецлар һәм коммунистлар җиңүне теләмиләрмени? Юк, сез җиңүне телисез. Ләкин сез техниканы, эшне үзләштермәгәнсез.

Серго заводта производствоны оештыруга үзе тотына. Ул тәҗрибәле работникларны сайлап ала, заводны корыч, чуен һәм башка кирәк-яраклар белән тәэмин итүне оештыра. Эшчеләрнең торак шартларын яхшырта, туклану мәсьәләсе яхшыра, культура эше юлга салына.

Ярты айдан завод ышанычлырак эшли башлый. Темплар көннән-көн күтәрелә.

Проект буенча завод көненә 144 трактор бирергә тиеш иде, 1933 нче ел башына завод моны арттыруга ирешә.

Харьков трактор заводын төзү башланды һәм Серго тракторлар эшләп чыгаруны ныклы тәртипкә кую өчен, харьковлылардан Сталинград тәҗрибәсен өйрәнүне таләп итте. Чиләбе трактор заводын төзү эшенә дә ул җитәкчелек итте. Ул Чиләбе трактор заводының барлык сметаларын һәм проектларын үзе карап чыкты. Чиләбегә барды, төзелешкә һәм заводка кешеләр һәм җиһазлар белән ярдәм итте.

Җир сөрү белән бергә, транспорт средствосы да була алырлык яңа, универсаль трактор төзүнең инициаторы иптәш Сталин булды. Бу идеяне турыдан-туры иптәш Серго тормышка ашырды. Ул Сталинград һәм Харьков трактор заводларында эшләп чыгаруга хәзерләнгән беренче каласслы яңа машинаны булдыру буенча барлык эшләргә җитәкчелек итте.

Серго СТЗ—НАТИ типындагы чылбырлы яңа трактор төзү эше белән нык кызыксынды; беренче сынау тракторы белән Серго алдында җир сөрә башлагач та конструкторлар уңайсыз хәлдә калдылар. Ләкин Серго аларның рухын төшермәде:

—Ярар, бу беренче үрнәк бит,—диде ул. Икенчесе һич шиксез яхшы булыр. Эшләгез һәм теләгегезгә ирешерсез.

Икенче үрнәктәге яңа тракторны Серго Политбюро членнары алдында 1935 нче елны эшләтеп карады. Трактор канәгатьләнерлек табылды һәм Серго үлгән елны инде ул трактор колхоз кырларында массовый күләмдә кулланыла башлады.

Икенче бишьеллык турында партиянең XVII нче съезды резолюциясендә „Промышленностьны үстерүдәге җиңүләр авыл хуҗалыгын машина техникасы рельсләренә күчерүдә гаять зур унышларны тәэмин иттеләр“ диелә. Социалистик кыр стахановчылары алдынгы техниканы үзләштереп, һәр елны 7—8 миллиард пот бөртекле ашлык җитештерү турында иптәш Сталин лозунгысын тормышка ашыралар. Миллионнарча совет патриотларының ударникларча эшләве Сергога иң яхшы һәйкәл.

Зинаида Орджоникидзе.

И. В. Сталин, Г. К. Орджоникидзе һәм А. И. Микоян иптәшләр Тбилисидә 1926 нчы елда. (Революция музее экспонаты). ТАСС фотохроникасының репродукциясе.

ОНТЫЛМАС СЕРГО

Григорий Константинович (Серго) Орджоникидзе партиягә 1903 нче елны, 17 яшендә керде. Бу вакытта ул фельдшерлар мәктәбендә укый иде. Партиянең Тифлис комитетының тапшыруы буенча Серго Закавказье тимер юлының баш мастерскойларында революцион эш алып барды. Монда эшчеләр белән катнашып аларның тормышлары белән танышып, ул большевик агитатор һәм җитәкче сыйфатларын үзләштерде.

Иптәш Сталин җитәкчелегендә Серго Орджоникидзе Закавказьенең большевистик оешмаларында актив эш алып барды. Шул вакыттан башлап ул һәр вакыт халыкларның бөек юлбашчысының турылыклы дусты һәм көрәштәше булды.

1910 нчы елның ноябрендә Орджоникидзе Парижга Ильич янына барды. Ленин аны Париж якынында Лонжюмодагы большевистик партия мәктәбенә җибәрде. Лениннең тапшыруы буенча Орджоникидзе 1911 нче елның җәендә партиянең VI нчы конференциясен чакыру буенча уполномоченный булып Россиягә килде. 1912 нче елны Прагада булган конференциядә ул Үзәк Комитет члены итеп сайланды һәм Үзәк Комитетның Россия бюросы составына—Россиядәге революцион эшкә җитәкчелек итүче практик үзәк составына кертелде. Бюрога иптәш Сталин җитәкчелек итә иде.

Озак та үтми, Сергоны кулга алалар. Бу аның дүртенче тапкыр кулга алынуы була. Беренче тапкыр Серго төрмәгә 1904 нче елны эләгә: патша полициясе аны Гори станциясендә бер төргәк революцион әдәбият белән тота 1906 нчы елның январенда ул Гудаут янында (Абхазия) корал бушаткан вакытта кулга алына 1907 нче елның ноябрендә Орджоникидзене янадан кулга алалар һәм Баиловский төрмәсенә ябыла, аннары Себергә сөрелә һәм аннан качып яшрен рәвештә Бакуга кайта.

1912 нче елны кулга алынгач Сергоны 3 елга Шлиссельбургка ябалар аннары Якутскига сөрәләр. Анда да ул армый-талмый большевистик эш алып бара.

1917 нче елны Орджоникидзе сөргеннән Петроградка кайта. Буржуазиянең һәм алпавытларның вакытлы хөкүмәтенә каршы, Советлар власте өчен көрәштә ул Лениннең һәм Сталинның якын көрәштәше була.

Июль көннәреннән соң Ленин подпольедә вакытта Серго аның янына барып йөри, Петроградтагы хәлне аңа белдереп тора һәм иптәш Сталинга тапшыру өчен анардан директивалар ала.

Серго РСДРП ның VI нчы съездында актив катнаша. Үзәк Комитетның тапшыруы буенча ул съездда доклад ясый һәм Лениннең буржуаз судка баруына кискен төстә каршы чыга. Халыкның хәзер фаш ителгән явыз дошманнары — Каменев, Рыков, Троцкий һәм башкалар исә Лениннең судка баруын яклаганнар иде.

Бөтен гражданнар сугышы чорында Орджоникидзе фронтның иң җаваплы участкыларында булды. 1918 нче елның җәендә Төньяк Кавказдагы иң авыр шартларда Серго большевик полководецлык һәм политик җитәкчелек сыйфатларын күрсәтте. Англия—Франция ялчысы генерал Деникинның бандалары Төньяк Кавказны Советлар Россиясеннән аердылар. Меньшевик Георгий Бичерахов Теректа Совет властена каршы мятеж башлады. Кисловодск районында Шкуро бандалары йөрде Болар барсы да хезмәтчел таулылар белән казаклар һәм крестьяннәр арасында өстен сыйныфлар тарафыннан ясалма рәвештә көчәйтелеп килгән дошманлыктан файдаланып Төньяк Кавказда Совет властен тар-мар итмәкче булдылар Ләкин аклар исәпләрендә ялгыштылар. Алар большевикларның һәм аларның җитәкчеләренең көчләрен исәпкә алмадылар.

„Гадәттән тыш комиссар“ Серго Орджоникидзе таулылардан кызыл революцион отрядлар төзеде. Ингушлар, чеченнар, осетинчар, кабардиннар, балкарлар Ленин—Сталин партиясенең чакыруына кушылып, үзләренен Совет властена ярдәмгә бардылар.

1919 нчы елның авыр февраль көннәрендә, Англия—Франция империалистлары тарафыннан яхшы тәэмин ителгән Деникинның офицерлар полклары үзләренен иң яхшы генералларыннан Врангель, Шкуро, Улагай һәм башкалар командалыгында Владикавказга якынлашкан вакытта, Орджоникидзе бер төркем батыр кызыл армеецлар белән, революцион таулыларның ярдәм итүе аркасында, акларның һөҗүмен туктатуга ирешә.

Дошманның шактый артык көчләренә каршы булган шушы канлы сугыш көннәрендә ингуш авылы Базоркинода акларның күз алдында Халык съезды җыелды. Бу съездда Орджоникидзе Совет хөкүмәте исменнән тау халыклары өчен автономияле республика төзелүне иглан итте.

Иптәш Сталин планы буенча Деникинны тәмам тар-мар итү, Төньяк Кавказда Советлар власте урнаштырылу Орджоникидзе һәм Киров иптәшләрнең исемнәре белән нык бәйләнгән.

1920 нче елның язында Орджоникидзе һәм Киров иптәшләр җитәкчелегендәге кызыл полклар Азербәйҗанга килеп керәләр, аннары Грузияне азат итәләр.

Орджоникидзе Закавказье большевикларының җитәкчесе була. С. М. Киров белән берлектә Серго Ленин—Сталин милли политикасын тормышка ашыра. Орджоникидзе һәм Киров иптәшләр җитәкчелегендә Закавказьедәге күп санлы халыкларның туганлык республикасы—Закавказье Федерациясе төзелә.

Халык хуҗалыгын торгызудан аны реконструкцияләүгә күчү чоры илебездә социализм төзү тарихында иң кыен чор булды. Бу чорда партия иптәш Орджоникидзегә гаять җаваплы эш—ҮКК-РКИ җитәкчесе булу эшен тапшырды. Бу постта Серго 1926 нчы елдан 1930 нчы елга кадәр эшләде.

Илне индустрияләштерүнең Сталинчыл планын җимерергә маташкан контрреволюцион троцкичыларга, зиновьевчыларга, бухаринчыларга каршы ҮКК председателе Серго Орджоникидзе кискен көрәш алып бара. Үзенә хас булган революцион дәрт белән Серго партиянең төп юлын, аның сафларының чисталыгын саклый.

1930 нчы ел ахырында Орджоникидзе ВСНХ председателе итеп, ә аннары авыр промышленность наркомы итеп билгеләнә. Бу постта да ул үзен гүзәл җитәкче итеп, Сталинчыл җитәкчелек стиле мастеры итеп күрсәтә.

Яңа төзелгән заводларны үзләштерүгә иптәш Орджоникидзе аеруча игтибар бирә.

Орджоникидзе совет хуҗалык работникларын Сталинча тәрбияләп үстерә. Ул алар өчен дус, остаз һәм игтибарлы ата булды. Ул кешеләрнең үсүен игтибар белән күзәтте, аеруча сәләтле работникларны күтәрде.

Авыр промышленностьта туган стахановчылык хәрәкәтенә Орджоникидзе гаять зур игтибар бирде. Ул заводларның һәм шахталарның иң яхшы стахановчылары белән киңәште, алардан өйрәнде һәм аларны өйрәтте. Орджоникидзе ун меңнәрчә хатын-кызларны—хуҗалык работникларының һәм инженер-техник работникларның хатыннарын актив политик һәм хуҗалык тормышына тартты.

Киң күңелле һәм эчкерсез Серго социалистик промышленностьның күренекле кешеләрен табып күтәрә, промышленностька яңалык кертүчеләрне һәм уйлап табучыларны төрлечә яклый. Шахтерлар—Стаханов һәм Изотов, корыч коючы Мазай, фрезеровщик Гудов, инженер Юси һәм бөтен дөнья күләмендә рекордлар биргән йөзләрчә һәм меңнәрчә башка стахановчылар—ул тәрбияләп үстергән кешеләр һәм аның шәкертләре.

Завод һәм фабрика эшчеләре, бөтен Совет иле аны стахановчылар наркомы дип атады.

Алексей Стаханов үзенең наркомы белән беренче очрашуы турында болай сөйли: „Бөтен промышленность җитәкчесе белән шахталардагы һәм заводлардагы эшчеләрнең шушылай бергә очрашулары бары тик безнең илдә генә мөмкин дигән уй ирекле-ирексез башка килә. Ләкин башка юлбашчыларыбыз кебек үк, иптәш Орджоникидзенең дә эшчеләр сыйнфы белән бер каннан, бер тәннән икәнлеген, аның халыкның иң яхшы улларыннан берсе икәнлеген илебездәге һәрбер хезмәт иясе яхшы белгәнлектән, бу гаҗәпләндерә аламыный?“

Орджоникидзе Ленин һәм Сталин белән берлектә һәм алар җитәкчелегендә большевиклар партиясен төзегән, илебездә социалистик революциянең җиңүе өчен, социализмның җиңүе өчен көрәшкән карт большевиклар гвардиясеннән иде.

Эшчеләр сыйнфы эшенә хиянәт итүчеләргә, халык дошманнарына һәм сатлык җаннарга Серго революцион сугышчыда була торган бөтен дәрт белән ташланды.

Орджоникидзе үзенең көчләре чәчәк аткан чакта сугышчан постта үлде.

Серго Орджоникидзенең данлыклы исмен бөек Ватаныбызның хезмәт ияләре бер кайчан да онытмаслар, аның героик образы халык йөрәгендә мәңге сакланыр.

Серго Орджоникидзе исме Совет халкын Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә яңа көрәшләргә, яңа җиңүләргә чакыра.

И. Разгон.

Чит илләрдә

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә, Линьхэ шәһәрендә японнарның 4 мең кешелек отряды урнашкан. Шушы көннәрдә кытай гаскәрләре сугышып Линьхэ шәһәренә бәреп кергәннәр. Япон частьләре каршы тора алмыйча Линьхэдән көнчыгыштарак Уйюаньга чигенгәннәр. Японнарның 600 дән артык кешеләре үлеп калган. Кытайлар 196 ватык йөк автомобиле алганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Кытайлар артиллериясе японнарның Сяошаньнән көньяк-көнчыгыштарак булган фортификация ныгытмаларын җимергән. Бу райондагы команда пунктлары барсы да диярлек кытай гаскәрләре кулында.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин тирәләрендә сугышлар дәвам итә.

16 февраль. (ТАСС).

КЫТАЙДАГЫ ХӘЛ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ ХӘРБИ ЭКСПЕРТЛАРЫ

НЬЮ-ЙОРК, 16 февраль. (ТАСС). Ассошиэйтед пресс агентлыгы Кытай фронтларындагы хәлне аңлатып, болай дип яза:—чит ил хәрби экспертлары японнар үзләренең теләкләренә ирешә алмыйча Кытайда алга баруларын туктаттылар дип саныйлар. Хәзер японнар Кытай армиясенә каршы кискен һөҗүм алып барырлык хәлдә түгел, чөнки аларның сугыш резервлары кими бара. Шунлыктан Кытайның тәмам җиңүгә ышанычы арта.

Экспертларның фикренчә, японнарның тагын да һөҗүм итү өчен армияне тәэмин итәргә хәлләре житми. Шул ук вакытта алар Кытайның кирәкле әйберләр ала торган юлларын да өзә алмыйлар. Хәрби экспертларның әйтүләренә караганда, гомуми исәпләүләр буенча японнарның инде бер миллион кешесе үтерелгән һәм яраланган. Японнарның бер миллион гаскәре Кытай гаскәрләренә һәм партизаннар отрядларына каршы көрәшү өчен Кытайның оккупацияләнгән территориясенә сибелгәннәр. Кытайларның атака ясаулары уңае белән япон гарнизоннары һәр жирдә дә акырынлап көчсезләнә баралар. Шунлыктан японнар зур көч туплап яңа объектларга зур һөҗүмнәр ясый алмыйлар.

Хәрби экспертларның белдерүенә караганда, Япония—Америка сәүдә килешүенең срогы тулганнан соң Японияңең баш командованиесе газолин һәм бомбалар расходын иң ким күләмгә кадәр кыскартырга бойрык биргән. Үткән атнада Гуанси провинциясендә японнарның бары 30 самолеты гына очкан.

Экспертлар, үткән елның октябрендә японнарның Чанша янында җиңелүләре борылыш пункты булды дип белдерәләр. Монда японнар гаскәрләрнең җитмәве һәм үз гаскәрләренең хәрәкәтләрен координацияләү булмау аркасында беренче тапкыр җиңелүгә дучар булдылар. Японнар тарафыннан үткәрелгән соңгы 8 операциянең японнар бары өчесендә генә уңышка ирештеләр, калган хәлләрдә барсында да кытайлар японнарны тар-мар иттеләр.

Васильево урта мәктәбенең (Юдино районы) 9 нчы класс укучыларыннан бер төркем чаңгыларда 16 километр арада хәрбиләштерелгән поход үткәрде. РӘСЕМДӘ: укучылар походта. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

АТУ СПОРТЫ КЛУБЛАРЫ ЯРЫШЫ

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез ФлотыныңXXII еллыгы хөрмәтенә Казандагы ату спорты клублары ярыш үткәрделәр.

Осоавиахимның Шәһәр Советы клубы ярышта беренче урынны алды. Клуб командасы, мөмкин булган 1.000 очкодан 913 очко алуга иреште. Казан Дәүләт университетының ату спорты клубы икенче урынны (886 очко), Химия-Технология институты клубы өченче урынны (885 очко) алдылар.

Ату спортының аерым мастерларыннан Химия-Технология институты студенты иптәш Магницкий 200 очкодан 188 очко җыеп, индивидуаль ярышта беренче урынны алды.

Мондый ярышлар Бөтенсоюз күләмендә үткәрелә. Ярышларда иң яхшы күрсәткечләр биргән ату спорты клублары халыкара ярышларда катнашу өчен кандидат итеп билгеләнәчәкләр.

КИНО-ТЕАТРЛАРДА

Шәһәрнең барлык кино-театрларында данлыклы Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты көненә багышланган күргәзмәләр оештырыла. Бәйрәм көннәрендә кино-театрларда оборона картиналары барачак.

Кино-театрларның фасадлары Кызыл Армиянең тарихын һәм хәзерге тормышын чагылдырган темаларга каратылып бизәләчәк. „Электро“ кино-театры—„Гражданнар сугышы фронтларында Кызыл Армия“, „Унион“—„Ленин—Сталин Кызыл Армияне оештыручылар“, „Рот-фронт“—„Кызыл Армиянең хезмәтияләренә туганнарча ярдәме“, „Чаткы“—„Кызыл Армиянең Хасан күле районындагы сугышларда күрсәткән батырлыгы“, „Красная Звезда“—„Халхын-Гол һәм Көнбатыш Украина, Көнбатыш Белоруссия фронтларында Кызыл Армия“ дигән темаларда бизәлә.

2 нче февральдән 23 нче февральгә кадәр барлык кино-театрларда да Кызыл Армия сугышчылары кинога бушлай җибәреләләр. Юбилей көнендә Кызыл Армия командирлары, политработниклары һәм сугышчылары өчен өстәмә сеанслар биреләчәк. Татарстанның кинофикация тресты юбилей көнендә Кызыл Армия частьләрендә кино хезмәте күрсәтү өчен тавышлы күчмә кино билгеләп куйды.

Район үзәкләрендәге стационар кинолар да да, шулай ук колхоз кино-театрларында да Кызыл Армия көненә багышланган кино-картиналар күрсәтеләчәк.

КЫЗЫЛ АРМИЯ РАЙОНЫНДА МАССОВЫЙ ОБОРОНА ЭШЕ

Кызыл Армия районында хезмәт ияләренең Осоавиахим сафларына кереп, хәрби эшкә өйрәнүгә һәм сугыш техникасын үзләштерүгә ымтылышлары чагыштыргысыз үсте. 1939 нчы елда 680 кеше, ә 1940 нчы елның январенда гына да 316 кеше Осоавиахим оешмасына член булып керде. Район буенча 25 ПВХО түгәрәге, 23 ГСО, 25 Ворошиловча атучылар һәм 25 противогаз өйрәнү түгәрәкләре эшли. Бу түгәрәкләргә барлыгы 1.509 кеше тартылган. Соңгы вакытларда 328 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына һәм 414 кеше „ПВХО“ значогына нормалар тапшырды.

„Алга № 1“, „Восход“, „Комбайн“ колхозларында, Каргали урта мәктәбендә, Шахмай тулы булмаган урта мәктәбендә массовый оборона эшләре аеруча яхшы оештырылган. „Алга № 1“ колхозы янындагы Осоавиахим оешмасында (җитәкчесе иптәш Галәветтинов) 1938 нче елда 47 член булса, хәзер 84 член исәпләнә. Каргали урта мәктәбендә дә членнар саны 60 ка җитте. Шахмай тулы булмаган урта мәктәбендә соңгы көннәрдә 28 кеше, „Восход“ колхозында 24, „Комбайн“ колхозында 18 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшырдылар. Мондый оешмалар районда аз түгел.

Районда массовый оборона эшләрен җәелдерүгә игтибарсыз караучы оешмалар да юк түгел әле. Мәсәлән, „Ирек“, „Беренче Май“, „Үрнәк“, „М. Чермшан“, „Большевик“, „Хунар“ колхозлары һәм район җир бүлеге, элемтә бүлеге җитәкчеләре массовый оборона эшенә бөтенләй әһәмият бирмиләр. Бу колхозларда һәм учреждениеләрдә оборона эшләрен оештыруга ВКП(б) райкомы, райкомол һәм Осоавиахимның район советы җитәкчеләре дә тиешле игтибар бирмиләр. Моны райондагы 198 коммунистның бары тик 90 ы, 790 комсомолецның 333 е генә Осоавиахимда член булып торулары белән дә күрсәтергә була.

Районда шушы көнгә кадәр тир оештырылмаган, бер генә оешмада да хәрби эшне өйрәнү буенча күргәзмә пособиеләр булдырылмаган.

К. Исламов.

АКТАШ РАЙОНЫНДА

Акташ районының колхозчылары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгын оборона эшләрен җанландыру белән каршылыйлар. Январь аенда 392 колхозчы Осоавиахимга член булып керде, Осоавиахимның 12 яңа башлангыч оешмасы төзелде. РОКК оешмасының эше шактый көчәйтелде, январь һәм февраль айларында 21 яңа оешма төзелде. РОКК җәмгыятенә 265 кеше член булып керде. Аларның күбесе данлыклы еллык көненә ГСО значогына норма тапшыруга хәзерләнә.

„Всход“ колхозының Осоавиахим оешмасы 10 кешене Ворошиловча атучы итеп хәзерләде. 13 колхозчы „ГСО“ значогына чаңгы буенча норма тапшырачак. „Красная заря“ колхозының оборона түгәрәкләре җитәкчесе колхозчы иптәш Яковлев 12 кешене Ворошиловча атучы итеп хәзерли. Ильич исемендәге колхозда 34 колхозчы Осоавиахимга член булып керде. Шулардан 12 кеше Кызыл Армия еллыгы көненә „ПВХО“ значогына, 6 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр.

23 нче февральдә Осоавиахимның район советы ату ярышлары һәм 30 километрга чаңгы чабышы оештыра.

МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең 22 еллыгы якынлашу уңае белән Мамадыш районында оборона эше шактый җанланды. Призывниклардан 159 кеше Осоавиахимга член булып керде һәм хәзер оборона түгәрәкләренә йөри. Осоавиахимның Яковка авылындагы оешмасында (председателе иптәш Якимов) һәм спирт заводы янындагы оешмасында (председателе иптәш Ефимов) Кызыл Армия көненә кадәр барлык призывникларның да ПВХО һәм „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшыруларына ирешү өчен көрәш бара.

ҮЗЕШЧӘНЛЕК СӘНГАТЕ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

Промкооперация членнары үзешчәнлек сәнгате белән бик нык кызыксыналар. Казандагы һәм районнардагы артельләр янында күп кенә түгәрәкләр төзелде. Казан сәүдә работниклары клубында промкооперация членнарыннан төзелгән рус һәм татар драма түгәрәкләре, хор түгәрәкләре эшли. „Конфексион“ артелендә балет, „Азат Хатын“ артелендә татар драма түгәрәкләре эшләп киләләр.

Шушы көннәрдә Казанда промкооперация членнарының балаларыннан балет, җыр һәм музыка түгәрәкләре төзелә.

„Промкооператор“ артеленең үзешчәнлек сәнгате түгәрәге Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы бәйрәме уңае белән 23 нче февральдә концерт куярга хәзерләнә.

Политик агарту работниклары өчен курслар

РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты авыллардагы политик агарту работниклары өчен 1939 нчы елны читтән торып уку курслары оештырган иде. 1939 нчы елның 25 нче октябреннән 25 нче ноябренә кадәр ярты еллык укуны йомгаклау буенча районнарда өч көнлек семинарлар үткәрелде. Саба, Мөслим, Балык Бистәсе, Чаллы, Мамадыш һәм Әтнә районнары читтән торып укучыларны оештыру эшендә аеруча уңышлы эшләделәр. Бу районнарның инструкторларыннан алдынгы иптәшләр бүләкләнделәр. Шушы елның 15 нче февраленнән 15 нче мартына кадәр районнарда еллык уку йомгаклары буенча өч көнлек семинарлар үткәрелә.

ЯҢА АВТОБУС ЛИНИЯЛӘРЕ

Татарстан Автомобиль транспорты идарәсе тарафыннан Казанда 4 маршрут буенча яңа автобус линияләре ачылды. Автобуслар Ершов кырыннан Яңа Бистәгә, Эсперанто урамыннан Кызыл Армия бистәсенә, Казан—Столбище һәм Казан—Югары Ослан арасында йөриләр. Автобуслар Казаннан Столбищега һәр көн 4 әр тапкыр, Югары Осланга 2 шәр тапкыр китәләр.

Татарстанда

— Татарстан Автомобиль транспорты идарәсенең автомобильләрен ватылудан саклау өчен Киров урамында профилактика мастерское төзелә. Автомобильләр шушы мастерскойда системалы рәвештә тикшереләчәкләр һәм ремонт кирәк булган автомобильләр төзәтү өчен калдырылачаклар. Шуның аркасында аварияләрне шактый киметергә мөмкин булачак.

— Питрәчтәге „Гончар“ артеле балчыктан художестволы савытлар эшләп чыгаруны үзләштерде. Анда һәр төрле матур вазалар, гөл банкалары, балалар өчен күп төрле уенчыклар житештерелә.

— Чүпрәле районының „Победа“ колхозы клубында трансляция пункты оештырылды. Радио тыңлау өчен урамга, 10 колхозчы йортына, авыл советы бинасына, мәктәпкә һәм башка учреждениеләргә репродукторлар куелды.

ЮЛ ТӨЗҮЧЕЛӘР ЯРЫШЫ

Теләче районында Кызыл байраклы „Марс № 2“ колхозы членнары юл төзү эшендә Ферганә каналы төзелеше методларын куллану турында Столбище районы колхозчыларының мөрәҗәгатен тикшереп, Татарстанның XX еллыгына кадәр Казан—Мамадыш арасындагы Зюри трактын тоташтан таш җәелгән юлга әйләндерү турында конкрет йөкләмә алдылар һәм Теләче, Питрәч, Саба, Кызыл Йолдыз районнарының барлык колхозчыларын ярышка чакырдылар.

„Марс № 2“ колхозы членнары 10 нчы февральгә кадәр 200 кубометр таш, 15 нче мартка кадәр 200 кубометр ком ташып бетерү турында йөкләмә алдылар. Бу йөкләмәләрне үтәү өчен барлык чаралар күрелә. Моңа кадәр юл төзү материалларын ташу эшендә даими рәвештә 10 ат белән бер бригада эшли иде. Хәзер бу бригадага тагын 20 ат беркетелде.

Х. Әхмәтҗанов.

БЕР СОВХОЗ УРНЫНА ИКЕ СОВХОЗ

Казаннан 30 километрда булган Кулай совхозы 4 ферманы берләштерә. Фермаларның икесе Питрәч районында, икесе Столбище районында урнашкан. Шуның өстенә бу совхозга Лаиш районыннан 860 гектар болын участкысы беркетелгән.

Фермалардан рациональ файдалану таләбе белән Татарстан Халык Комиссарлары Советы бу совхозны икегә бүлүне кирәкле тапты. Питрәч районындагы ике фермага 4.432 гектар жир участкысы, Лаиш районыннан 400 гектар болын, Столбище районындагы ике фермага 2.853 гектар жир участкысы һәм 460 гектар болын бирелә.

Совхозларның берсенә иптәш Калинин исемен, икенчесенә иптәш Микоян исемен бирү турында үзәк каршында үтенеч кузгатылды.

МТС ЛАРДА ЯҢА ТӨЗЕЛЕШЛӘР

Быел Татарстан МТС ларында яңа төзелешләр алып бару өчен 1 миллион 500 мең сум капитал салына. 7 МТС та ремонт мастерскойлары төзелә. Балык бистәсе, Арча һәм Юдино районнарында 3 яңа МТС оештыру өчен 240 мең сум билгеләнде. Аларда складлар, машина саклау урыннары һәм торак йортлары төзеләчәк. 7 МТС та узган ел салына башлаган ремонт мастерскойларын һәм складларны төзеп бетерү өчен 525 мең сум җибәрелде.

КИЕЗ ИТЕК ФАБРИКАСЫ ЭШЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ЯҢА ЙОРТ

Казан киез итек фабрикасы эшчеләре өчен быел Газовый урамда 30 квартиралы яңа йорт салына башлый. Аны төзү өчен 1940 нчы елга 600 мең сум акча билгеләнде. Әгәр дә бу сумма срогыннан элек үзләштерелсә, йортны төгәлләү өчен быел ук өстәмә сумма җибәреләчәк.

СУД

Талаучылар

Шәһәрнең Молотов районында Е. Н. Прокофьев дигән җинаятьче талаучылар группасы оештырган. Группада катнашучылар шәһәр урамнарында күп кенә кешеләрне талаганнар. Агалы-энеле Николай һәм Александр Куликовлар Эсперанто урамында Рогожин һәм Домов дигән кешеләрне талаганнар.

7 кешедән торган бу группаның эше Молотов районының 4 нче участкы халык судында каралды. Прокофьев (икенче фамилиясе Китаев) һәм Николай Куликов 3 әр елга, Александр Куликов, К. П. Ситнов, З. А. Перльштейн 2 шәр елга, Н. Н. Косов һәм И. М. Маркелов берәр ел ярымга ирекләреннән мәхрүм ителүгә хөкем ителделәр.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Тапталганнар. Нәриман урамында 68 нче йортта торучы Гарәфи Шәрәфеттинев 4 нче маршрут трамвай вагоны туктап житкәнче утырмакчы булган, ләкин тагылма вагон астына егылган. Аның сул аягы өзелгән. Ю. Долгашев дигән 9 яшьлек малай Свердлов урамында трамвай вагонына асылынып барган вакытта тагылма вагон астына егылып төшеп, уң аягын өздергән. Аларның һәр икесен авыр хәлдә больницага җибәргәннәр.

БЕЛДЕРҮ

19 нчы февраль, кич 6 сәгатьтә, ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия Мәгарифе йортында, ВКП(б) тарихы буенча систематик курс циклыннан—„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ ның 1 нче бүлегенә карата лекция үткәрелә. Лекция татар телендә була. Тема: „Россиядә крепостнойлык хокукының бетерелүе һәм промышленность капитализмының үсүе“. Лектор — иптәш Гыймади.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Су станциясе территориясендә „ДИНАМО“ ның
ЧАҢГЫ СТАНЦИЯСЕ
БГТО һәм ГТО буенча I һәм II нче баскыч нормалар тапшыру өчен, шулай ук коллектив һәм индивидуаль рәвештә чаңгыда йөрергә чыгу өчен файдаланырга, махсус ботинкалары белән, чикләнмәгән күләмдә
чаңгылар бирә
Ботинкалары белән чаңгылардан файдалану өчен бер сәгатькә түләү бәясе: индивидуаль аучылар өчен 1 сум, коллектив рәвештә алу өчен—75 тиен.
322—3—1

Казан Дәүләт Медицина институтының тире авырулары клиникасындагы
косметика һәм гигиена
КАБИНЕТЫНДА
(Толстой урамы, 4, телефон 33—79)
сыткыларны, бетчәләрне, сипкелләрне, миң, сөял кебек тиредәге төрле кимчелекләрне дәвалау, биткә массаж ясау, тирене тәрбияләү, чәчне дәвалау һәм доцентлар тарафыннан консультацияләр бирү эшләре алып барыла.
Кабул итү—түләүле, гомуми ял көннәреннән башка һәр көн көндез 4 сәгатьтән кич 7 гә кадәр.
2427—1

МЕДФАРПРОМНЫҢ 1 НЧЕ ФАРМЗАВОДЫ
профессор С. В. Моисеев күрсәткәнчә хәзерләнгән һәм Наркомздрав Гыйлми Медицина Советы тарафыннан рөхсәт ителгән
Посеребренный ПЕСОК № 56
дигән исем белән йөртелә торган дару эшләп чыгарды
Посеребренный песок № 56
һичбер төрле зарары булмаган, антисептик, бактерияләрне үтерү буенча гаять көчле дару. Көнкүрештә бу көмешле су сыйфатындагы дарудан түбәндәге максатлар өчен бик гади рәвештә файдаланыла: эчү өчен, теш тазарту, авыз һәм тамакны чайкау өчен, киптерелгән фруктыларны һәм яшелчәләрне зарарсызландыру өчен. Дәвалану максатлары буенча: шешү процесслары булганда, җәрәхәтләрне юу-тазарту, ангина булганда тамакны чайкау һәм башкалар өчен.
Куллану буенча тулы мәглүматлар тартма эчендә.
АПТЕКАЛАРДА САТЫЛА
Тартмасы 100 грамм, 2 сум 25 тиен.
Урыннарда булмаса мөрәҗәгать итү өчен адрес: Ленинград, Аптекарский проспект, 6, Фармзавод № 1 Медфарпрома.

КИРӘК:

Таткинотрестка МАШИНИСТКА һәм КИНО-ТЕАТРЛАРДА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ПИАНИСТЛАР. Трестның кадрлар бүлегенә килергә. Бауман урамы, 60.
254—2—2

Юллар идарәсенең 257 нче участкысына тракторлар һәм юл машиналары буенча, шулай ук автохуҗалык буенча МЕХАНИКЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Чехов урамы, 24. Телефон 40—46.
287—2—1

ГИДУВ ка даими эшкә БУХГАЛТЕРЛАР, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, КОЧЕГАРЛАР, СЛЕСАРЬЛАР һәм ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР. Казан, Комлев урамы, 11.
151—2—2

„Азат Хатын“ артеленә даими эшкә СКОРНЯКЛАР, МАШИНАДА ТЕГҮЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР, БҮРЕКЧЕЛӘР, ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ ӨЧЕН ХИСАПЧЫ, ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, ЦЕХ БУХГАЛТЕРЛАРЫ һәм скорняк тегү машиналары буенча СЛЕСАРЬ. Хезмәт хакы килешү буенча.
145—2—2

Таткинотрестка даими эшкә БУХГАЛТЕРЛАР, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, ХИСАПЧЫЛАР һәм КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ МАШИНИСТКА. Казан, Бауман урамы, 60. Баш бухгалтерга килергә.
155—2—2

Даими эшкә МЕЖРАЙМЕХАНИКЛАР, ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, ПРАКТИК СТАЖЛЫ МЕХАНИКЛАР һәм МЕХАНИК-МАШИНИСТЛАР. Казанда эшләү өчен БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОРЛАР һәм районнарда эшләү өчен БАШ БУХГАЛТЕРЛАР. Центрозаготзерно Татарстан Республика конторасының кадрлар бүлегенә килергә. Ухтомский урамы, 11/16. Телефон 36—48.
224—2—2

„Динамо“ ның Татарстан Республика советына ТӘҖРИБӘЛЕ МАШИНИСТКА кирәк. Чернышевский урамы, 12/20 адресы буенча килергә, яисә 34—91 телефоны буенча шалтыратырга.
316—3—2

Казмехкомбинатның скорняк-тегү производствосы үзәк лабораториясенә, ХАТЫН-КЫЗ ӘЙБЕРЛӘРЕ БУЕНЧА МОДЕЛЬЕР-КОНСТРУКТОР. Хезмәт хакы килешү буенча. Яңа бистә, Кызыл Татарстан урамы, 3.
296—1

Казан күн-сбруйлар фабрикасына даими эшкә, КҮН КИСҮЧЕЛӘР, ШОРНИКЛАР, КОЧЕГАРЛАР, ХЕЗМӘТНЕ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ТЕГҮ МАШИНАЛАРЫ БУЕНЧА МЕХАНИКЛАР, АЯК КИЕМНӘРЕ ҺӘМ КҮН ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ТЕХНИКЛАР, ДӘГВАЛАР БУЕНЧА ҖАВАПЛЫ ҮТӘҮЧЕ ҺӘМ МЕТАЛЛ БУЕНЧА ТОКАРЬЛАР. Ягодный бистәсе Краснококшай урамы, 39, кадрлар бүлеге.
292—1

Казан тимер юл буфетлары конторасына, урыннарда эшләү өчен, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР ҺӘМ ПЛАНОВИКЛАР. Шартлары турында сөйләшергә килү өчен адрес: Казан, Париж Коммунасы урамы, 16.
323—2—1

14 нче трестның Транспорт конторасына БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ ҺӘМ АЕРЫМ БАЛАНС БУЕНЧА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Хезмәт хакы килешү буенча.
319—3—1

Автокузов заводына (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) КОНСТРУКТОР, ЯЗУ МАШИНАСЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ МАШИНИСТКА, БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ, МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЫ, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, НОРМАЛАУЧЫ, ТЕХПРОПАГАНДА БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕ, ХЕЗМӘТ БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ, АГАЧ һәм БУЯУ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА ТЕХНОЛОГЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча.
181—2—1

Архитектура-Планлаштыру мастерскоена даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ-ПЛАНОВИК. Казан, Чернышевский урамы, 1 өченче кат, 36 нчы бүлмә.
220—3—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 18 нче февральдә
көндез БАНКРОТ (талон 118)
кич КҮЗЛӘР (талон 119)
19 һәм 20 нче февральдә
Булак арты „республикасы“
Талоннар: 19 нда 120, 20 ндә 121.
Спектакльләр көндез 12 дә, кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык.
ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 18 нче февральдә көндез һәм кич, шулай ук 20 нче февральдә кич
Бакчалар чәчәк ата
Талоннар: бүген көндез 21, кич 104.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КИРОВ РАЙОНЫНДАГЫ
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
Яш Тамашачылар театры спектакльләре
Бүген, 18 нче февральдә көндез һәм кич
СКАЗКА
Талоннар: көндез 54 һәм 55, кич 56 һәм 57.
Спектакльләр көндез 12 сәгатьтә һәм кич 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының
ГАСТРОЛЕ
СТРАТОС—3
Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем элмәкләре һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты
М. ЗОЛЛО гастрольләре дәвам итә.
18 нче февральдә зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында
—АНОНС—
ИРЕК операсы
Билетлар ТДАТ кассасында алдан сатыла.
Операга коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Яңа фильм ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДИҢГЕЗ ПОСТЫ „СЕДОВЧЫ ГЕРОЙЛАРГА ДАН“ һәм „СОВЕТ СӘНГАТЫ“ киножурналлары күрсәтелә.
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	МИНИН һәм ПОЖАРСКИЙ
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да.	Инженер Кочинның ялгышуы
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	КАСТУСЬ КАЛИНОВСКИЙ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	СТЕПАН РАЗИН
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	УНБЕР БАШКАЛА

КУРСАНТЛАР УРНАШТЫРУ ӨЧЕН
3 ай срок белән
БҮЛМӘЛӘР КИРӘК
Түләү—килешү буенча. Тәкъдимнәр белән Казан Дәүләт Ветеринария институтының хуҗалык бүлегенә килергә.
270—2—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 723
ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД.
ЗАКАЗ № 657.